КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 декабрь

г.Казань

№ 1175

Метрополитенны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен раслау турында

«Урамнан тыш транспорт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль законның 7 һәм 9 статьялары, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Метрополитенны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 21 декабрендәге 468 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Метрополитенны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин